**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«05» 04 2022 ел                Яр Чаллы                № 1106

«2022 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында» 2021 елның 30 декабрендәге 4702 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексын, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатында

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлга ашыруның кыска вакытлы планына үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштырып халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе                А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 202_ елның ____ ____________ ______ номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган 2022 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруның кыска сроклы планы

## I. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның әлеге кыска сроклы планы (алга таба - кыска сроклы план) Россия Федерациясе Торак кодексы, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 21.07.2007 ел, 185-ФЗ номерлы Федераль закон), «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә региональ программаны тормышка ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү срокларын төгәлләштерү, күпфатирлы йортларда гомумимөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең планлаштырылган төрләрен төгәлләштерү, дәүләт ярдәме төрләрен һәм күләмен билгеләү, капиталь ремонт үткәрүгә муниципаль ярдәм күрсәтү максатында эшләнгән.

## II. Кыска вакытлы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска вакытлы планның төп максатлары булып тора:

Татарстан Республикасында торак фондын саклау, торгызу һәм сыйфатын арттыру;

гражданнарган имин һәм уңайлы яшәү шартлары тудыру;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм.

Кыска вакытлы планның төп бурычлары булып тора:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

кыска вакытлы планны башкаручыларны сайлап алу буенча ачык һәм үтә күренмәле процедураларны эшләү һәм башкару;

чыдам материаллар һәм ресурсларны саклау технологияләрен кулланып, капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чаралар һәм комплекслылык куллану.

Кыска вакытлы планны тормышка ашыру срогы - 2022 ел.

Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру гомуми мәйданы 9,2 мең кв.метр булган 10 күпфатирлы йортта 495 гражданга имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

III. 2022 елда күп фатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләме

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эш күләме |
|---|---|---|
| Түбә ремонтлау | мең кв. метр | 4,20 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, шул исәптән: | | |
| салкын су белән тәэмин итү | мең метр | 0,146 |
| су бүлү | мең метр | 0,158 |
| Фасадны җылыту һәм ремонтлау | мең кв. метр | 6,406 |

IV. Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрүне өлешләп финанслау күләмнәрен нигезләү

Кыска вакытлы планга кертелгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлауны өлешләп финанслау күләмнәрен исәпләү Федераль законның 18 статьясы 3 өлеше нигезендә, региональ программага кертелгән күпфатирлы йортлар исемлегеннән, Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау эшләренең смета бәясеннән, кыска сроклы планга кертелгән күпфатирлы йортларга карата эшләр исемлегеннән һәм күләменнән чыгып башкарылды.

Кыска вакытлы планны Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән өлешләп финанслауның минималь өлеше Федераль законның 18 статьясы нигезендә билгеләнгән һәм 70 процент тәшкил итә (мәгълүмат Фондның рәсми сайтында урнаштырылган).

V. Ресурслар белән тәэмин итү

Кыска вакытлы планны финанслау чыганаклары булып Фонд, Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яки) җирле бюджетлар, торак милекчеләре ширкәтләре, торак, торак - төзелеш кооперативлары (алга таба - ТСЖ, ЖК, ЖСК) әгъзалары яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары яисә күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре акчалары тора.

Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме 39690807,65 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты - 5774740,00 сум;

җирле бюджетлар - 6719000,00 сум;

ТСЖ, ЖК, ЖСК яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яисә күпфатирлы йорттагы биналар милекчеләре - 13303075,12 сум.

2022 елда күп фатирлы йортларга капиталь ремонт ясау өчен финанс чараларының ихтыяҗы күләме

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслау ихтыяҗы, млн. сум |
|---|---|
| Түбә ремонтлау | 25,83 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, шул исәптән: | |
| салкын су белән тәэмин итү | 0,212 |
| су бүлү | 0,368 |
| Фасадны җылыту һәм ремонтлау | 11,896 |
| ПСД эшләү һәм экспертиза | 1 |
| Техник күзәтчелек | 0,383 |

Капиталь ремонт үткәрү бәясе күрсәтелгән күпфатирлы йортлар исемлеге, шул исәптән фонд акчалары исәбеннән, кыска вакытлы планга 1 кушымтада күрсәтелгән.

## VI. Капиталь ремонт буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләрнең чик бәясе

20__елга күпфатирлы йортларда биналарның гомуми мәйданының 1 кв.метрына исәпләнгән капиталь ремонт буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик бәясе 14 мең сум тәшкил итә.

Әлеге кыска сроклы планга кертелгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен чик чыгымнар нормативлары эш төрләре буенча Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба - Министрлык) тарафыннан раслана.

Капиталь ремонт буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик хакын арттыру, шулай ук кыска сроклы планда каралмаган хезмәтләр һәм (яки) эшләр өчен түләү капиталь ремонт өчен кертем рәвешендә түләнә торган күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

## VII. Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру механизмы

Әлеге кыска сроклы планны тормышка ашыру Министрлык, «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы Фонды» коммерциясез оешмасы (алга таба - Региональ оператор), Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, җирле үзидарә органнары, торак - коммуналь хуҗалык, торак-коммуналь хуҗалык, идарәче оешмалар, биналарның милекчеләре, подрядчы оешмалар (алга таба - кыска сроклы планны үтәүчеләр) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Министрлык:

кыска вакытлы планны башкаручылар белән хезмәттәшлекне, кыска сроклы план чараларын тормышка ашырганда аларның эшчәнлеген координацияләүне һәм тикшереп торуны оештыра;

региональ программаны тормышка ашыруның муниципаль кыска сроклы (еллык) планнарын карый һәм алар тарафыннан финанс ярдәме бирү шартларының үтәлешен тикшерә;

күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау өчен Фонд акчаларын алган көннән алып җиде көн эчендә акчаларны кыска сроклы план нигезендә җибәрү турында карар кабул итеlә;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауны өлешләп финанслау турында шартнамә нигезендә фонд һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын күчерә;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауны үз вакытында башкаруны тәэмин итү максатында региональ оператор белән хезмәттәшлек итә;

җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырыла торган хисапларны анализлау нигезендә кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру һәм финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәү мониторингын гамәлгә ашыра;

кыска вакытлы планны гамәлгә ашыруның барышы һәм финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәү турында хисапны һәм хисап чорында региональ оператор, җирле үзидарә органнары биргән белешмәләр нигезендә Татарстан Республикасы хисабын Татарстан Республикасы Президентына раслауга җибәрә, үзенең сайтында урнаштыра;

үз сайтында кыска вакытлы планга кергән күп фатирлы йортлар исемлеген урнаштыра;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнаша, шул исәптән тиешле тәртипне раслау юлы белән дә;

үз компетенциясе кысаларында кыска вакытлы план чараларын гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны оештыра.

Региональ оператор:

идарәче оешмалар белән дефектлы ведомстволар әзерләүгә, шулай ук түләү документларын формалаштыруга һәм торак милекчеләреннән капиталь ремонтка кертемнәрне региональ оператор исәбенә кертүне тәэмин итүгә килешүләр төзи;

проект документларын әзерләүгә, төзелеш контролен гамәлгә ашыруга, шулай ук күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкаруга подряд шартнамәләре төзи;

законнарда билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау өчен подрядчы оешмаларны сайлап алуны гамәлгә ашыра;

күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау, проект документларын эшләү, закон таләпләре нигезендә төзелеш контроле буенча хезмәтләрне һәм (яки) эшләрне финанслауны гамәлгә ашыра;

идарәче оешма, муниципаль берәмлек, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе, төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма, бина милекчеләренең

вәкиле белән килештерелгән КС-3, КС-2 формалары нигезендә подрядчы оешмаларга башкарылган эшләр өчен түләүне башкара;

күпфатирлы йортта биналарның һәр милекчесе буенча акча керүне исәпкә ала;

кыска сроклы планны гамәлгә ашыру кысаларында Министрлыкка соратып алына торган документлар һәм белешмәләр тапшыралар;

законнарда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе:

капиталь ремонт эшләрен башкаруның дефектлы ведомостьларын һәм күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү буенча муниципаль адреслы программаларны, программаларны тормышка ашыруның кыска сроклы планнарын килештерә;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау өчен подрядчы оешмаларны сайлап алу процедурасында катнаша, капиталь ремонт үткәрү өчен квалификацияле һәм намуслы подрядчы оешмаларны җәлеп итүне контрольдә тота;

күпфатирлы йортка капиталь ремонтның вакытында һәм сыйфатлы башкарылуын тикшереп тора;

КС-2 формасы буенча башкарылган эшләр актларын килештерә;

капиталь ремонт тәмамланган объектны эксплуатациягә кабул итүдә катнаша;

подряд шартнамәләре реестрын алып бара;

капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау турында милекчеләрнең җыелышларының беркетмәләрен исәпкә алып бара;

министрлыкка кыска сроклы планны гамәлгә ашыру кысаларында соратып алына торган документларны һәм белешмәләрне тапшыра.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары:

Федераль закон нигезендә финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне раслаучы Региональ программаны гамәлгә ашыруның муниципаль кыска сроклы (еллык) планнарын һәм документларын формалаштыралар һәм министрлыкка җибәрәләр;

министрлыкка муниципаль берәмлек тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне раслаучы норматив хокукый актларның күчермәләрен һәм башка документларны тапшыралар;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнашалар;

КС-2 формасы буенча башкарылган эшләр актларын килештерә;

Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм торак законнары нигезендә әлеге кыска сроклы план белән билгеләнгән күләмдә капиталь ремонт эшләрен финанслашуга җирле бюджет акчаларын күчерәләр;

капиталь ремонт буенча эшләрне кабул итү актларын, күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау өчен чыгымнар сметасында каралмаган акчалардан, шулай ук аннан арткан очракта, килештерәләр;

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча эшләр башкаруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тоталар;

Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль берәмлек буенча кыска сроклы планны гамәлгә ашыру максатында мәгълүматлар базасын булдыралар һәм актуаль халәттә тоталар;

Министрлыкка Фондка хисаплар формалаштыру өчен кирәкле документларны һәм белешмәләрне тапшыралар.

ТСЖ, ЖСК, ЖК, идарәче оешмалар:

тикшерү актларын, капиталь ремонт буенча эшләр күләменә дефектлы ведомостьлары килештерәләр;

дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алып, проект документациясен әзерләүне тәэмин итәләр.

Министрлык тарафыннан расланган тәртип нигезендә сайлап алуны оештыручы булалар;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнашалар;

капиталь ремонт объектларына кертүне гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонтның үз вакытында һәм сыйфатлы башкарылуын контрольдә тоту, шулай ук аларны капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү актларына һәм файдалануга тапшыру актларына кул кую хокукы белән кабул итүдә катнашалар.

Бина милекчеләре:

тикшерү актларын, капиталь ремонт буенча эшләр күләменә дефектлы ведомостьлары килештерәләр;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонтның үз вакытында һәм сыйфатлы башкарылуын контрольдә тоту, шулай ук аларны капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү актларына һәм файдалануга тапшыру актларына кул кую хокукы белән кабул итүдә катнашалар.

Подрядчы оешмалар:

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча эшләрне подряд килешүендә билгеләнгән срокларда башкаруны тәэмин итәләр;

КС-2, КС-3 формасы буенча башкарылган эшләр актларын формалаштыралар;

подряд шартнамәсендә каралган башка эшләрне башкаралар.

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы массакүләм мәгълүмат чараларында кыска вакытлы план чараларын гамәлгә ашыру барышын даими яктыртуны гамәлгә ашыра.

Кыска вакытлы планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинг «Торак фонды мониторингы» бердәм мәгълүмат продуктында гамәлгә ашырыла.

## VIII. Күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтен капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкару өчен подрядчы оешмаларны сайлап алу тәртибе

Подрядчы оешмалар региональ оператор, җирле үзидарә органнары, муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан Министрлык расланган Тәртип нигезендә сайлап алына.